**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге**

**КАРАР**
**14.12.2020 ел**

**КАРАР**
**№16**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2021 нче елга һәм 2022, 2023 нче еллар план чорына бюджеты турында**

“Россия Федерациясенлә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Иске Имән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Иске Имән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Статья 1

1.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2021 нче елга бюджетының төп характеристикасын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 3 192,9 мең сум күләмендә;
2) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгымнары күләме 3 192,9 мең сум;
3) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,0 мең сум.

2.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2022 нче елга һәм 2023 нче елга бюджетының төп характеристиксын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2022 нче елга фаразланган кеременең гомуми күләме 3 269,5 мең сум һәм 2023 нче елга 3 352,3 мең сум күләмендә;
2) 2022 нче елга гомуми чыгымнары күләме 3 269,5 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 85,0 мең сум күләменлә, һәм

2023 нче елга 3352,3 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвешә расланган чыгымнар 170,0 мең сум күләмендә.

3) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2022нче елга 0,0 мең сум һәм 2023 нче елга 0,0 мең сум.

3.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2021 нче елга һәм 2022, 2023 нче еллар план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

Статья 2

1.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2022 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча буычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2022 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычының югары чиген 0,0 мең сум кләмендә расларга.

3.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2023 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча буычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

Статья 3

Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетында 2021 нче елга һәм 2022, 2023 нче еллар план чорына фаразланган керем күләмен карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

Статья 4

1. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген шушы карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген шушы карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

Статья 5

1.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының 2021 нче елга һәм 2022, 2023 нче еллар план чорына чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге

бюджетының бүлекләр, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге муниципаль программалары һәи эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), 2021 нче елга һәм 2022, 2023 нче еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне карарның 6 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге муниципаль программалары һәи эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча 2021 нче елга һәм 2022, 2023 нче еллар план чорына бүлүне әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә расларга.

4. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2021 нче елга 0,0 мең сум, 2022 нче елга 0,0 мең сум, 2023 нче елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

Статья 6

1.Иске Имән авыл җирлеге бюджетының 2021 нче елга, төзелгән килешүләр нигезендә, мәдәният хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү буенча шартлар тудыру буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен 1 623,2 мең сум, 2022 нче елга 1 685,3 мең сум, 2023 нче елга 1 750,4 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга.

2. 2021 нче елда Иске Имән авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны күчерү квартал саен башкарыла дип билгеләргә.

Статья 7

Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетында Сарман муниципаль районы бюджетыннан алына торган акчаны исәпкә алырга:

1)2021 нче елга бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр – 2 451,3 мең сум, 2022 нче елга – 2 523,9 мең сум, 2023 нче елга – 2598,2 мең сум;

2) 2021 нче елга хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр – 100,0 мең сум, 2022 нче елга – 101,0 мең сум, 2023 нче елга- 105,1 мең сум

Статья 8

1.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2021 нче елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук муниципаль учреждение хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Статья 9

1.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге исеменнән төзелгән товарларга, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләргә муниципаль контрактларның 2020 елда түләнергә тиешле шартлары нигезендә түләнергә тиешле муниципаль контрактларның үтәлүенә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калган суммасыннан артмаган күләмдә Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2021 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә.

Статья 10

Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгының казначылык органнары төзелгән киешүләр нигезендә Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

Статья 11

Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (PRAVO TATARSTAN. RU) һәм Татарстан Республикасы “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

Статья 12

Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан көченә керә.

Статья 13

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Имән авыл җирлеге Советы рәисе: Р.Ә.Исламова